КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 декабрь г.Казань № 1131

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 909 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 909 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 декабрь, 1298 нче; 2022 ел, 26 гыйнвар, 47 нче; 2023 ел, 2 май, 556 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«VIII. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторы

Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары:

1) үткән ике календарь ел өчен бер социаль хезмәт күрсәтелүчегә исәпләгәндә турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмасы белгечләренең штат саны 20 проценттан артык кимү;

2) ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм һәркем файдалана алырлык башка ресурслардан алына торган бер үк урнашу урыны буенча өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә яисә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә, яисә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче ике һәм аннан күбрәк контрольдә тотылучы затларның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары турында белешмәләр җыю, аларны эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алу барышында ачыклау;

3) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче контрольдә тотылган зат тарафыннан файдаланыла торган бинаны яки урынны авария һәм (яки) җимерек хәлдә дип тану;

4) социаль хезмәт күрсәтү оешмасы тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча кимендә 50 балл алу.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин